# КАРАР

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Ильдеряк авыл җирлеге составына керүче Тарханка торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында

2019 елның 18 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендәге 111 номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында " карары», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Ильдеряк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 24 статьясы нигезендә Аксубай муниципаль районының Иске Ильдеряк авыл җирлеге Тарханка 2019 елның 18 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: "Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлегенең Тарханка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлар, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- авыл эчендәге автомобиль юлларын кышкы чорда торак пунктта тоту.
-Тарханка авылы урамнары буйлап поселок эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау, ком һәм вак таш салу)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
- җыенда катнашучылар исемлегенә 125 кеше кертелгән;
- җыенда катнашучылар саны 64 кеше.

Гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышлар түбәндәгечә бүленде:

- «РИЗА» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 64 кеше тавыш бирде;
- «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар итте:
1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге составына керүче Тарханка авылында гражданнар җыенын – узган дип, ә халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2.Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:
«Сез килешәсезме:
1). 2020 елда Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлеге Тарханка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш) 300 сум күләмендә үзара салым кертү;
2). түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:
- Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- авыл эчендәге автомобиль юлларын кышкы чорда торак пунктта тоту.
-Тарханка авылы урамнары буйлап поселок эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау, ком һәм вак таш салу)?»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: htt: //pravo.tatarstan.ru.
4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Ильдеряк авыл җирлеге башлыгы: В. К. Әлмәткин